| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

«28» май 2024 ел            Алабуга шәһәре            № 348

Алабуга муниципаль Советының «Алабуга муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазифаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, рәисе урынбасарына, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Алабуга муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазифаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, рәисе урынбасарына, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1. пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи окладлары күләменә тапкырлап исәпләнә, ул 13 323 сум тәшкил итә.».

1.2. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.2. пунктының 3.2.4. пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.1. пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата бүләкләү вазифаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.».

1.4. Нигезләмәнең 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районында Алабуга муниципаль районы Башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының акчалата түләү күләмнәре

| Вазифа исемнәре | Айлык акчалата түләү, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 37 037 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 33 331 |
| Депутат | 17 950 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 15 256 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 33 331 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 29 976» |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш һәм 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетның икътисади үсеше, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов